КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 ноябрь

г.Казань

№ 1464

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар тормыш иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе уставын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2010 ел, 1 апрель, 216 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 03 июль, 471 нче, 2017 ел, 22 декабрь, 1027 нче, 2018 ел, 27 июнь, 525 нче, 2018 ел, 24 октябрь, 946 нчы, 2022 ел, 25 май, 486 нчы, 2022 ел, 05 декабрь, 1284 нче карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Балалар тормыш иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.7 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктның 2.4.1 пунктчасының дүртенче абзацында «министрлыклар, ведомстволар» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«билгеләнгән тәртиптә республика башкарма хакимият органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан кирәкле мәгълүмат соратып алырга;»;

унтугызынчы абзацта «предприятиеләргә, учреждениеләргә,» сүзләрен төшереп калдырырга;

егерменче абзацта «предприятиеләр, учреждениеләр,» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1 пунктта:

18 пунктчада «башкарма хакимиятенең дәүләт органы» сүзләрен «дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләренә алмаштырырга;

19 пунктчада «башкарма хакимиятенең дәүләт органы» сүзләрен «дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 935 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1339 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин